**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**«ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«27» март 2017 ел № 13/4

**Тукай муниципаль районында авыл халкының эшлекле активлыгын арттыру һәм кече хуҗалык формаларын үстерү чаралары турында**

«Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2016 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, авыл халкының эшлекле активлыгын арттыру, 2016 ел өчен конкурска йомгак ясау һәм 2017 елга бурычлар билгеләү буенча зона киңәшмәләренең 1 номерлы беркетмәсе нигезендә муниципаль берәмлек Совет

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Мәгълүматны исәпкә алырга.
2. Район Башкарма комитетына:
   - гражданнарны шәхси хуҗалыкларны үстерү, 2018-2020 елларга район бюджетын формалаштырганда авыл хуҗалыгы продукциясен арттыру, хуҗалык итүнең кече рәвешләренә финанс ярдәме күрсәтү максатыннан чыгып, авыл хуҗалыгы формаларына финанс ярдәме күрсәтүне күздә тотарга;
   - «2030 елга кадәр стратегия» кысаларында авылда кече хуҗалык формаларын үстерү программасын кабул итәргә (2017 елның 1 маена кадәр);
   - гамәлдәге авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары эшенә анализ ясарга һәм аларга матди-техник базаны үстерүгә грант ярдәме программасында катнашырга тәкъдим итәргә.
3. Авыл җирлекләре башлыкларына тәкъдим итәргә:
   - шәхси ярдәмче хуҗалыкларны саклап калу һәм терлекләрнең баш санын киметмәү буенча эзлекле эш алып бару,
   - хуҗалык итүнең кече рәвешләрен үстерүгә ярдәм итү буенча федераль, республика һәм муниципаль программаларны гамәлгә ашыру буенча аңлату эшләре алып барырга.
4. Тукай районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә тәкъдим итәргә:
   - халыктан сатып алына торган продукциянең барлык төрләренә дә сатып алу бәяләренең нигезле булуына даими контроль үткәрергә;;
   - район фермерлары ассоциациясе белән берлектә авылда эшмәкәрлеккә ярдәм итү программаларында катнашу өчен эшмәкәр кешеләрне сайлау

буенча эш алып барырга, бизнесны үстерү өчен шартлар тудырырга.;

- шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга шәхси ярдәмче хуҗалык алып барганда җитештерелгән һәм эшкәртелгән авыл хуҗалыгы продукциясен сатуда тулы ярдәм күрсәтергә.

5. «Якты юл» («Светлый путь») газетасы редакциясенә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баруның уңай мисалларын даими рәвештә бастырып чыгарырга тәкъдим итәргә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл хуҗалыгы, җир төзелеше, экология һәм табигый ресурслар буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе В.Г. Хаҗиев